| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ КИЕКЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле авылы **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Заречная ур., 14Б адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Торговая ур., 19 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Совет ур., 44 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2019 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Комсомол ур., 6нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Заозерная ур., 5нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы

Киекле авыл җирлеге Киекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Күл арьягы ур., 5нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының алтынчы этабын уздыруны билгеләргә.

7. Киекле авылында яшәүчеләрнең исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча эшләргә.

8. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

9. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) торак пункт урамнарын ремонтлау өчен материаллар сатып алу (эре таш, балчыклы ком, вак таш катнашмасы, кулланылган асфальт-бетон, кирпеч ватыклары) һәм сатып алынган материалларны урамнарга түшәү, торак пункт чикләрендәге юлларны паспортизацияләү эшләрен башкару.

2) Халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү эшләрен башкару өчен материаллар, җиһазлар сатып алу.

Эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшырту буенча чаралар үткәрү.

- Су алу скважиналарын лицензияләү өчен документлар пакетларын эшләү һәм аларны су алу скважиналары территориясендәге җиһазларга, документларга карата куелган лицензия таләпләренә туры китерү.

- Югарыда күрсәтелгән чаралар буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү.

3) Авыл урамнарын һәм зиратларны сезонлы карап тоту, торак пункт территорияләрен һәм зиратларны төзекләндерү.

4) Урамнарны яктырту системасын сатып алу, урнаштыру, приборлар һәм җайланмалар урнаштыру, башкарылган эшләр, чаралар буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

5) Массакүләм һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

10. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле

авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Р.М.Ганиев